ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында” Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында” 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3, № 4, № 7 (I өлеш); 2016, № 1 – 2), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

**“2 статья**

Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен (сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны кертеп) ваклап сату рөхсәт ителми:

1) 22 сәгатьтән алып 10 сәгатькә кадәр, авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр дип танылა торган оешмалар, крестьян (фермер) хуҗалыклары, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан Россия Федерациясе илкүләм стандарты нигезендә “ресторан”, “кафе”, “бар” типларына кертелгән, куллanучыларга хезмәт күрсәтү залы булган җәмәгать туклануын оештыру объектларында (алга таба – җәмәгать туклануы объектлары) җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтелгәндә мондый оешмалар, крестьян (фермер) хуҗалыклары, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сатудан, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны ваклап сатудан, шулай ук пошлинасыз сату кибетләрендә алкоголь продукциясен ваклап сатудан тыш;

2) стационар булмаган җәмәгать тукланүы объектларында (1 майдан алып 1 октябрьгә кадәрге чорда кулланучыларга хезмәт күрсәтү залы булган сезонлы (җәйге) кафеларда сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны ваклап сатудан тыш);

3) күпфатирлы йортларда, шулай ук күпфатирлы йортларга өстәп төзелгән, кушып төзелгән, кушып-өстәп төзелгән биналарда урнашкан җәмәгать тукланүы объектларында, “ресторан”, “кафе” типларына кертелгән җәмәгать тукланүы объектларыннан тыш;

4) шәһәр җирлекләрендә урнашкан, гомуми мәйданы 50 квадрат метрдан ким булган җәмәгать тукланүы объектларында (сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны ваклап сатудан тыш);

5) сатып алучылар (кулланучылар) өчен керү урыны күпфатирлы йортның ишегалдыннан оештырылган “ресторан”, “кафе” типларына кертелгән җәмәгать тукланүы объектларында һәм күпфатирлы йортларда урнашкан сәүдә объектларында.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2017 ел, 05 апрель
№ 14-ТРЗ